**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2022 елның «17» гыйнварыннан № 11

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 24 октябрендәге 429 нчы номерлы, 2018 елның 27 декабрендәге 625 нче номерлы, 2018 елның 27 декабрендәге 631 нче номерлы карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2016 елның 27 июлендәге 293 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 24 октябрендәге 429 нчы номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буенча уза торган маршрутлар буенча авыр йөкләр, зур габаритлы йөкләрне автомобильдә йөртүгә карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 27 декабрендәге 625 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы

чикләрендә даими йөртүнең муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 10 нчы июль, 270 нче номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 631 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:// pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л.К. Исхакова